| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

10.06.2020 — № 390

Татарстан Республикасының Нурлат муниципаль районы составына керүче җирлекләр бюджетлары территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасының Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертларны бүлү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142 статьясы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 31 октябрендәге 988 номерлы карары белән территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 12 маендагы 928-р номерлы күрсәтмәсе белән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләрне Татарстан Республикасы бюджетыннан (башка бюджетара трансфертларны) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торучы Нурлат муниципаль районы һәм авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында» 2019 елның 26 декабрендәге 248 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлатского муниципального района Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә

юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә бирелә торган башка бюджетара трансфертларны территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә 2020 елга компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә бүлүне кушымта нигезендә расларга:

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Кушымта

**Территориаль иҗтимагый үзидарә системасын үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган башка бюджетара трансфертларны территориаль иҗтимагый үзидарә җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыру өлешендә бүлү**

| № | Авыл җирлеге атамасы | Трансферт күләме (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Нурлат шәһәре | 1 350 000,0 |
| Барлыгы: | | 1 350 000,0 |